СОВЕТ
МОЛВИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУЛЛА ИЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** КАРАР

_12.11.2025___ № __13___

Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен Кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " №131 – ФЗ, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Зеленодольск муниципаль районының Мулла Иле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы вәкаләтләренен бер өлешен Кабул итәргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мулла Иле авылындагы күлне чистарту.

2. Мулла Иле авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3 Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) , шулай ук Мулла Иле авылы, Яна урам, 3 (җирлекнең административ бинасы), Мулла Иле авылы, Үзәк урам, 17а йорты (мәдәният йорты бинасы),Зур Отәк авылы , Яшел урам, 21а йорты (мәдәният йорты бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга

Мулла Иле авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Г.Сәлахиев